Татарстан Республикасы

# ЗАКОНЫ

## "Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында" Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 31 гыйнварында
кабул ителде

**1 статья**

"Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында" 2001 елның 24 гыйнварындагы 595 номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 1 – 2; 2005, № 1 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"16 статья. **Агрохимикатларның һәм пестицидларның туры килүен мәҗбүри раслау**

Агрохимикатларның һәм пестицидларның туры килүен мәҗбүри раслау техник җайга салу турында Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2013 елның 16 феврале
№ 12-ТРЗ